КАБИНЕТ МИНИСТРОВ РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ МИНИСТРЛАР КАБИНЕТЫ

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

2023 ел, 23 август г.Казань № 1002

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «2023 елга Татарстан Республикасы дәүләт мөлкәтен хосусыйлаштыруның фараз планы (программасы) турында» 2022 ел, 8 ноябрь, 1186 нчы карары белән расланган 2023 елга Татарстан Республикасы дәүләт мөлкәтен хосусыйлаштыруның фараз планына (программасына) үзгәрешләр кертү хакында

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты КАРАР БИРӘ:

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «2023 елга Татарстан Республикасы дәүләт мөлкәтен хосусыйлаштыруның фараз планы (программасы) турында» 2022 ел, 8 ноябрь, 1186 нчы карары белән (Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2023 ел, 18 апрель, 491 нче карары белән кертелгән үзгәрешләрне исәпкә алып) расланган 2023 елга Татарстан Республикасы дәүләт мөлкәтен хосусыйлаштыруның фараз планына (программасына) түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

II бүлекнең «Акцияләрен 2023 елда хосусыйлаштыру планлаштырыла торган акционерлык җәмгыятьләре исемлеге» бүлекчәсенең «Таткоммунэнерго» республика җитештерү берләшмәсе» акционерлык җәмгыяте, Татарстан Республикасы, Казан шәһәре» юлында:

3 нче графада «96,5» саннарын «96,6» саннарына алмаштырырга;

5 нче графада «1» санын «0,92» саннарына алмаштырырга;

Татарстан Республикасы
Премьер-министры А.В.Песошин